Дәрес барышы.

1. СЛАЙД Уку – иң яхшы белем.
   -Сез бу мәкальне ничек аңлыйсыз?
   - Ул нәрсә турында?
   -Сез моның белән ризамы?
   -Бу мәкал нәрсәгә өйрәтә? (җаваплар)
   -Сез дәресне башларга әзерме? (әзер)
   -Әйдәгез бүгенге дәресне шушы девиз астында үткәрәбез!
   Сезнең алыгызда бәяләү таблиасы. Һәр биремнән соң үзегезгә бәя куячаксыз.

   Тактага карыйк әле.
   2. СЛАЙД Урамда, шуалар, балалар, чаңгыда.
   -Болар нәрсәләр икән? (сүзләр)
   Әйдәгез җөмлә төзибез. (Урамда балалар чаңгыда шуалар.)
   -Бу нәрсә? (җөмлә)
   -Каян белдегез? (фикер тәмамланган???)
   -Ә нәрсә соң ул җөмлә? (тәмамланган уйны белдерә)
   -Бу җөмләдә сүз нәрсә турында бара? (балалар)
   -Балалар сүзе нинди сорауга җавап бирә? (кемнәр)
   Кем? соравына җавап биргән сүз җөмләдә ия була.
   -Балалар нишлиләр? (шуалар)
   -Сорау куегыз. (нишлиләр)
   Нишлиләр соравына җавап биргән сүз җөмләдә хәбәр булып килә.
   Димәк, балалар – ия, шуалар – хәбәр. Ия белән хәбәр җөмләнең баш кисәкләре дип атала.
   Әйдәгез, тагын тактага карыйбыз.

   3. СЛАЙД Декабрь – кыш ае.
   -Бу җөмләнең иясен һәм хәбәрен әйтегез. (декабрь)
   -Нинди сүз төркеме белән белдерелгән? (Ия исем белән белдерелгән, хәбәр исем белән белдерелгән)
   Әгәр ия белән хәбәр исем белән белдерелсә, араларында сызык куела.

   4. СЛАЙД Көн матур.
   Җөмләнең иясе белән хәбәре нинди сүз төркемнәре белән белдерелгән? (иясе исем, хәбәре сыйфат)
   Нәтиҗә: Димәк, бүгенге дәреснең темасы нинди? (ия белән хәбәр, җөмләнең баш кисәкләре)
   Безнең дәреснең максаты:
   1. җөмләдә ия белән хәбәрне дөрес табарга өйрәнү.
      Укытучы сүзе: Дәфтәрләрне ачабыз. Бүгенге числоны һәм дәрес темасын язабыз. Китапларны 35 биттә ачабыз, анда кагыйдә бар.

Укыйбыз. Слайдта җөмләләр бирелгән. Бу җөмләләрне дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз һәм баш кисәкләрен табыгыз.

5. слайд.

Яфрак- яфрак кар ява. Ак күбәләктәй карлар җир өстенә куналар. Зәп-зәңгәр күкне болыт каплап ала. Ә кар төшә дә төшә. Ул балаларның алсу битләренә, озын керфекләренә куна.

6. слайд. Готовый җавапны чыгарырга тикшерү өчен.

- биремне эшләгәндә нинди авырлыклар белән очраштыгыз? (кагыйдәне искә төшерү)

Үзбәя бирү.(таблица)

7 слайд. Төшеп калган сүзләрне куеп язарга.

Менә ... җитте. Урамда ап-ак ... ява. ... урамга уйнарга чыктылар. Коля белән Алина кар тавы ... . Аларга ... булышты.

Балалар шатланышып чана ... . Алар шатланышып өйләренә кайтып ... .

Тикшереп чыгу. Хаталарны төзәтү.

8 слайд. Готовый җавапны чыгарырга тикшерү өчен.

Үзбәя бирү.(таблица)

Физкультминутка.

Кыш турында шигырь уку яки салмак музыка тыңлау. Слайдлар белән. (табигать күренеше) 5-6 слайд шигырьләр белән

9 слайд . Җөмләләрне төзеп бетерергә. (Карточкалар белән эш.)

Сәламәт булу өчен, ...

Сәламәт булу өчен, ...

Сәламәт булу өчен, ...

Сәламәт булу өчен, ...

Тикшерү. Уку, җыеп алу.

- Нинди авырлыклар белән очраштыгыз
  Үзбәя бирү.(таблица)

10 слайд. Төшеп калган репликаларны куеп әйт.

- ...
- Мин кышны яратам.
- ...
- Кышын чаңгыда, тимераякта шуабыз.
- ...
- Мина Яңа ел бәйрәме ошый.
- ...
- Кышкы каникулны авылда үткәрергә телим.

Тикшерү.

- Нинди авырлыклар белән очраштыгыз
  Үзбәя бирү.(таблица)

11 слайд. Җөмләләр төзеп әйт. Тактага язу.

Как скажешь о том, что: (Репликалар язу)
- На улице зима.
- Через 24 дня наступит Новый год.
- Вы пойдете в парк на каток.
- Скоро будут зимние каникулы.
- Ты любишь играть в хоккей.
-

Һәр җөмләне тактага язалар. Ия белән хәбәрнең астына сызалар. Тикшерү.

- Нинди авырлыклар белән очраштыгыз
  Үзбәя бирү.(таблица)

12 слайд.Картина белән эш.

<u>Сүзлек эше</u>

Песнәк-

Кызылтүш-

Җимлек-

- Рәсемдә нәрсә күрәсез?
- Кайсы ел фасылы?
- Балалар нишли?

Рәсемгә карап 5 җөмлә язарга. Дәфтәргә

- биремне эшләгәндә нинди авырлыклар белән очраштыгыз?

Үзбәя бирү.(таблица)

Нәтиҗә ясау.

1. Бүген без дәрестә нинди тема белән таныштык
2. Нинди авырлыклар белән очраштык
3. Нинди күнегүләр эшләдек.
4. Сез үзегезнең эшегезне ничек бәялисез

Үзбәяне җыеп алу.

Рәхмәт әйтү. Билгеләр кую.

Саубуллашу.